ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 205 от «01» 06 2020 г.

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 елның 27 гыйнварындагы
«Муниципаль белем бирү оешмаларын
Мамадыш муниципаль районының конкрет
территорияләренә беркетү турында»
28 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Мамадыш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга алуны тәэмин итү, укыту – тәрбия процессын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында һәм 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273- ФЗ Федераль Законның 9,55, 67 статьялары, Башкарма комитет турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 27 гыйнварындагы «Муниципаль белем бирү оешмаларын Мамадыш муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетү турында» 28 нче карарының 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль белем бирү оешмаларын Мамадыш муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетү турында".

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р. Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәржеманов

0000010481